Республика Татарстан

Исполнительный комитет
Менделеевского
муниципального района

Татарстан Республикасы

Менделеевск муниципаль
районы
башкарма комитеты

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

07.11.2022 ел Менделеевск ш. №687

Төбәк дәүләт төзелеш күзәтчелеге органына шәһәр төзелеше эшчәнлеген тәэмин итүнең мәгълүмат системасында капиталь төзелеш объектын сүтеп бетерү һәм бу хакта мәгълүмат җиткерү һәм документлар урнаштыру буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2020 елның 30 декабрендәге 509-ФЗ Федераль законны үтәү йөзеннән, Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы башкарма комитетының 2020 елның 12 мартындагы 173 номерлы карары белән расланган төбәк дәүләт төзелеш күзәтчелеге органының шәһәр төзелеше эшчәнлеген тәэмин итүнең мәгълүмат системасында капиталь төзелеш объектын сүтеп бетерү һәм бу хакта мәгълүмат җиткерү турында муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентының 1 бүлегенең 1.5 пунктындагы 2 абзацын үзгәртергә һәм түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

« Мөрәҗәгать итүче - физик яисә юридик зат (дәүләт органнарыннан һәм аларның территориаль органнарыннан, бюджеттан тыш дәүләт фондлары органнарыннан һәм аларның территориаль органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан тыш) йә аларның дәүләт хезмәтләре күрсәтүче органга яисә муниципаль хезмәтләр күрсәтүче органга мөрәҗәгать иткән вәкаләтле вәкилләре йә "Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында" 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законның 1 маддәсендәге 2 һәм 3 өлешләрендә күрсәтелгән оешмаларга, «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр

күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законның 1 маддзсендәге 2 өлешендә күрсәтелгән экспертларга, «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законның 1 маддәсендәге 2 өлешендә күрсәтелгән белгечләргә яисә әлеге статьяның 5 пунктында күрсәтелгән оешмаларга дәүләт хезмәтләре күрсәтү яисә муниципаль хезмәтләр күрсәтү турында таләбе яисә шул исәптән дәүләт хезмәтләрен күрсәтү турында Федераль законның 7.1 маддәсендә билгеләнгән тәртиптә, шул исәптән 27.3 маддәсендә билгеләнгән тәртиптә күрсәтелгән дәүләт һәм муниципаль хезмәтләргә телдән һәм язма формада мөрәҗәгать итүче.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга» http://pravo.tatarstan.ru һәм Менделеевск муниципаль районының рәсми сайтында www.mendeleevsk.tatarstan.ru дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр бүлегендә урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Менделеевск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең төзелеш, торак-коммуналь хуҗалык буенча беренче урынбасары вазифаларын башкаручы А.Ф.Искаковка йөкләргә

Җитәкче Р.Р.Искәндәров